**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге составына керүче Борды авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

21 ноябрь 2025 ел № 1

2025 елнын 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнен бердэм системасында жирле узидарэне оештырунын гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елнын 28 июлендэге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районынын “Борды авыл жирлеге” муниципаль берэмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районынын Борды авыл жирлегенен 07.11.2019 ел 51/1 номерлы “Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районынын Борды авыл жирлеге составына керуче торак пунктларда гражданнар жыенын эзерлэу хэм уткэру тэртибе турында нигезлэмэне раслау хакында”гы карары нигезендэ 2025 елның 21 ноябрендэ узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2026 елда яшәү урыны буенча Борды авыл җирлеге Борды авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр, өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йоз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларнын гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзеклэндеру, ремонтлау)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 387 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 260 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 260 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда яшәү урыны буенча Борды авыл җирлеге Борды авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йоз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзеклэндеру, ремонтлау)

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова